Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы
Яңа Тумба авыл җирлеге Советы

# КАРАР

№ 83 «13» февраль 2019 ел

## Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге территориясендә инвалид балалары булган гаиләләргә һәм инвалидларга җир кишәрлекләрен аренда хокукында беренче чиратта бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Җир кодексы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Нурлат муниципаль районы территориясендә инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә җир кишәрлекләрен аренда хокукында беренче чиратта бирү тәртибе турында Нигезләмәне (алга таба-нигезләмә, теркәлә) расларга.
2. Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге Башкарма комитетына җир кишәрлекләре бирү өлкәсендә хокукый мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларны әлеге Нигезләмәгә туры китерергә.
3. Әлеге карарны Яңа Тумба авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Тумба авыл җирлеге Советы рәисе Л.Н. Осипов

Нурлат муниципаль районы
Яңа Тумба авыл җирлеге Советының
2019 ел, 13 февраль, 83 номерлы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге территориясендә инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә җир кишәрлекләрен аренда хокукында беренче чиратта бирү тәртибе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә инвалидларга һәм үз составында инвалид балалары булган гаиләләргә (алга таба-инвалидлар, йә мөрәҗәгать итүчеләр), «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача хуҗалыгы һәм бакчачылык (алга таба- җир кишәрлекләре) максатлары өчен арендалау хокукында беренче чиратта бирү тәртибен җайга сала.

1.2. Җир кишәрлекләрен бирү Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Җир кодексы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, әлеге Нигезләмә нигезендә башкарыла.

1.3. Җир кишәрлекләре бирү Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан тиешле гаризалар нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.4. Гариза бирүчеләргә арендалау хокукында җир кишәрлекләрен беренче чиратта бирү турындагы карар проектын әзерләүне «Нурлат муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесе гамәлгә ашыра.

1.5. Гариза бирүчегә алга таба беренче чиратта җир кишәрлеге формалаштыру гариза бирүче тарафыннан тәэмин ителә һәм мөрәҗәгать итүченең акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

1.6. Бер үк җир кишәрлегенә карата бердән артык гариза булса, соралган җир кишәрлеген бирү турындагы карар гариза бирүче файдасына кабул ителә.

1.7 Шул ук җир кишәрлегенә карата гариза бирүчеләрдән бердән артык гариза кергән очракта, соратып алына торган җир кишәрлеген бирү турындагы карар башкаларыннан элегрәк гариза биргән зат файдасына кабул ителә.

## 2. Инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү шартлары

2.1. Аренда хокукында җир кишәрлекләре гариза бирү датасына бер үк вакытта түбәндәге шартларга җавап бирә торган мөрәҗәгать итүчеләргә:

2.1.1. инвалид булган граждан һәм үз составында инвалид булган гаилә әгъзаларының барысы да Россия Федерациясе гражданнары булып, Нурлат муниципаль районы составына керүче җирлек территориясендә даими яшәү урыны буенча теркәлгәндә;

2.1.2. медицина-социаль экспертиза дәүләт хезмәте учреждениесе тарафыннан бирелгән инвалидлык билгеләү фактын раслаучы белешмә булганда;

2.1.3. инвалид булган гражданин һәм үз составында инвалид булган гаилә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәптә торганда;

2.1.4. инвалид булган гражданин һәм үз составында инвалид булган гаилә әгъзалары «Нурлат муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» МКУ алып бара торган чиратта торганда;

2.1.5. инвалид булган граждан һәм үз составында инвалид булган гаилә әгъзалары милек, даими (срогы чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлек мирас итеп биләү, торак төзелешенә бәйле максатларга бирелгән җир кишәрлеген арендалау (шул исәптән рөхсәт ителгән башка төр файдалану өчен: индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык, дача хуҗалыгы, бакчачылык) хокукы булмаганда;

2.1.6. инвалид булган граждан һәм үзенең составында инвалид булган гаилә әгъзалары әлеге Нигезләмәнең 2.1.5 пунктында күрсәтелгән гариза бирү датасына соңгы ике ел эчендә милек хокукын алу, җир кишәрлегенә (җир участогына, җир кишәрлегенең бер өлешенә) хокукны тапшыру (алу) буенча алыш-бирешләр башкармаган очракта бирелә.

2.2. индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлеге бирү максатларында, мәйданы муниципаль берәмлектә җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләре белән расланган иң чик минималь күләмнән кимрәк булган очракта, 2.1.5 һәм 2.1.6 пунктлары кулланылмый.

2.3. Җир кишәрлекләре беренче чиратта даими яшәү урыны буенча Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге составына керүче тиешле җирлек чикләрендә теркәлгән мөрәҗәгать итүчеләргә бирелә.

2.4.Мөрәҗәгать итүчеләргә беренче чиратта бирелә торган җир кишәрлегенең минималь һәм максималь күләме муниципаль берәмлекләрдә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә билгеләнә.

2.5. Гариза бирүчеләргә беренче чиратта җир кишәрлекләре бер тапкыр бирелә.

## 3.Инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә җир кишәрлекләрен беренче чиратта бирү тәртибе

3.1. Гариза бирүчеләргә җир кишәрлекләре арендага, беренче чиратта, сатуларны (аукционнарны) үткәрмичә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 маддәсе 2 өлеше 14 пункты, 39.15, 39.16, 39.17 маддәләре нормаларына туры китереп, киләсе тәртиптә бирелә:

1) җир участогын төзергә кирәк булган территорияне межалау проекты расланмаган очракта, җир участогы төзергә туры килсә, җир участогының урнашу схемасын әзерләү;

2) «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль закон нигезендә җир кишәрлеген төзергә яки аның чикләрен тәгаенләргә туры килгән очракта, вәкаләтле органга (Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетына) алдан килештерү турында гариза бирү;

3) җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында карар кабул итү;

4) җир кишәрлеген бүлү максатларында гариза бирүче тарафыннан җир кишәрлеген межалау проекты нигезендә, җир кишәрлеге чикләрен төгәлләштерү өчен кирәк булган җир кишәрлеге яисә кадастр эшләре схемасы нигезендә, җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән очракта, кадастр эшләрен башкаруны тәэмин итү;

5) җир кишәрлеге чикләрен аныклауга бәйле рәвештә җир кишәрлеге яки дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру;

6)  вәкаләтле органга (Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетына) җир кишәрлеген бирү турында гариза бирү;

7) җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү.

3.1.1. Гариза бирүчеләр тарафыннан җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза,  җир кишәрлеген бирү турында гариза, сайлап алу буенча КФҮ филиалына яисә почта элемтәсе аша кәгазьдә, яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып, шәхсән мөрәҗәгать итү юлы белән вәкаләтле органга (Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетына) тапшырыла  яисә җибәрелә.  Күрсәтелгән гаризаларны бирү тәртибе һәм ысуллары, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрен кулланып электрон документ формасында бирелгән очракта, аларның форматына карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте, федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана.

3.1.2. Мөрәҗәгать итүче вәкаләтле орган (Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты) тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша алынырга тиешле документларны тапшырырга хокуклы.

3.2. Гариза бирүчеләргә арендага җир кишәрлекләре бирү муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча административ регламентлар: Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 декабрендәге 1012 номерлы карары белән расланган алдан килешү нигезендә җир кишәрлеген бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты; Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 декабрендәге 1012 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.3. Гариза бирүчеләргә беренче чиратта бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләме Россия Федерациясе Җир кодексының 39.7 маддәсенең 5 өлеше 3 пункты нигезендә исәпләнә.